Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

16 декабрь 2024 ел

№ 34

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 26.04.2018 №14 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.04.2024 елгы №290 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»гә 26.04.2018 елгы №14 карарына (Советның 09.11.2020 №20, 19.10.2022 №25, 19.12.2022 №34, 20.08.2024 №17 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме билгеченең вазыйфаи окладын 13990 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2024 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4.Элеге карарны 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Саба шәһәр җирлеге Советының
16.12.2024 ел № 34 карарына
№1 кушымта

**Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгы, аның урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы вазыйфаи затларына акчалата бүләк күләме**

| Вазыйфа исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәһәр җирлеге башлыгы | 22 810 |
| Шәһәр җирлеге башлыгының урынбасары | 16 995 |
| Депутатлар | 13 990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13 990 |